СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

29.12.2018 № 24/2

На № _________ от_____________

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау»**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАРЫ:**

1. Кушымта нигезендә " Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 гыйнварындагы 11/5 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе

Ф. М. Камаев